КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 июль г.Казань № 606

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика экспертлар конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика экспертлар конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 июль, 502 нче; 2017 ел, 31 март, 203 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 807 нче; 2018 ел, 23 июль, 581 нче; 2020 ел, 29 июнь, 543 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика экспертлар конкурсы турындагы нигезләмәнең 2.1 нче пунктында «яшәү урыны яки булу урыны буенча теркәлгән» сүзләрен «яшәүче» сүзенә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика экспертлар конкурсын үткәрү комиссиясе составында:

комиссия составыннан А.Б.Гревцовны, В.Н.Демидовны, А.А.Фоминны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы, комиссия рәистәше Максим Владимирович Скирданы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы Марат Шамил улы Долговны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин